**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА СТЕПНООЗЕРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**БИКҮЛЕ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Бикүле ав. КАРАР

« 21» февраль 2022 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би күле авыл җирлегенең Бикүле авылында халык җыенын билгеләп кую турында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., муниципаль районның Бикүле авыл җирлеге Уставының 23 ст. нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 3 мартында 10 сәгать 00 минутта Бикүле авыл мәдәният йортында Би күле торак пунктында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Халык җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы һәм Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә дип билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Аны түбәндәге редакциядә раслап, элегрәк 22.11.2021 елның 2 номерлы расланган карарга үзгәреш кертергә ризамы?:

«Бикүле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан тыш, 2100 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә карата сез килешәсезме:

- Бикүле авылындагы торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау (грунтлы вак таш катнашмасыннан нигезен, вак таш белән сибү);
- күперне ремонтлау;
- Бикүле авылы су башнясына диспетчерлык пунктын урнаштыру;
- Бикүле авылында парк зонасын төзекләндерү;
- Бикүле авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы» http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) кирәк.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Бикүле авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Х. Садыйков